Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2 сентябрь, 2020 ел

№ 288

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасары, контроль-хисап палатасы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 133 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турында» (2018 елның 26 апрелендәге 140 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән), 2009 елның 4 декабрендәге 45 номерлы «Питрәч муниципаль районы Башлыгына, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы урынбасарына айлык акчалата бүләкләү турында» карарына, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт өчен түләү күләме турында» 2012 елның 25 декабрендәге 114 номерлы һәм «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен индексацияләү турында» 2012 елның 1 октябрендәге 817 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Индексацияләнгән, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында» 2013 елның 30 сентябрендәге 705 номерлы, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының акчалата түләүләре күләмнәрен, контроль-хисап органнары рәисләренең

һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2017 елның 28 июлендәге 525 номерлы карарлары нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасарының, контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата түләү күләмнәрен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

3. Муниципаль хезмәтнең үзләре биләгән вазыйфалары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен 2020 елның 1 октябреннән арттырырга. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге Карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Питрәч муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына элек үзләре кабул иткән хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы　　　　　　　　　　И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА